Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының
Иске-Рәҗәп авыл җирлеге Советы

# КАРАР

13.07.2021 ел №29-1

Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен кабул итү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Законының 15 статьясындагы 4 өлеше, «Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен тапшыру турында» Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Советының 11-4 номерлы карары, «Спас муниципаль районының Иске-Рәҗәп авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының 16 июльдәге 2019 ел 70-2 номерлы җирле үзидарә органнары арасында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен тапшыру турында килешүләр төзү тәртибен раслау хакында» Иске-Рәҗәп авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Җирле мәсьәләләрне хәл итү буенча «Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең вәкаләтләренең бер өлешен Кабул итәргә:

- социаль наем шартнамәсе төзү;
- муниципаль торак фондының торак урыннарын гражданнар милкенә тапшыру.

2. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Иске-Рәҗәп авыл җирлеге башкарма комитеты әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы җирле үзидарә органнары белән тапшыру турында килешү төзүне тәэмин итәргә.

3. Спас муниципаль районының рәсми сайтында http://www.spasskiy.tatarstan.ru, хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (//http:pravo.tatarstan.ru) закон белән билгеләнгән вакытта бастырып чыгару турында әлеге карарны бастырып чыгарырга.

Иске-Рәҗәп авыл җирлеге башлыгы М.Ә.Нугаев